## ХАЛЫК ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Көрнәле авыл җирлеге составына керүче Коры Көрнәле авылы

12 ноябрь 2019 ел. № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Көрнәле авыл җирлеге составына керүче Коры Көрнәле торак пунктында гражданнар җыены

**Карар итте**:

1. 2020 елда Көрнәле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан тыш, 400 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге чараларга юнәлдерергә:
- җирлек эчендәге юлларны карап тоту;
- суэтем башнясына насослар сатып алу;
- Коры Көрнәле авылын төзекләндерү.

3. Әлеге карарны Көрнәле авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Көрнәле авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Көрнәле авыл җирлеге башлыгы Х.А.Медведев